РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 886 15 июнь 2015 г.

# Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтнең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.2 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтнең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карарлар кабул итү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы бюджет һәм финанс департаментына йөкләргә.

Т. Х. Камалетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
2015 елның 15 июнендәге
886 номерлы карары белән
расланган кушымта

**Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтнең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карарлар кабул итү тәртибе**

**1. Төп нигезләмәләр.**

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль бюджет учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль автоном учреждениеләренә (алга таба - учреждениеләр), Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль унитар предприятиеләренә (алга таба - предприятиеләр) Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник җиһазлауга) һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр тарафыннан капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга субсидияләр рәвешендә җирле бюджеттан бюджет ассигнованиеләре бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен билгели (алга таба – карар, капиталь төзелеш объектлары, күчемсез мөлкәт объектлары, субсидия).

1.2. Карар проектын әзерләүнең инициаторы булып, җирле үзидарә органының функциональ (тармак) бүлекчәсе, Түбән Кама муниципаль районының муниципаль учреждениеләре һәм предприятиеләре (алга таба - тармак органы, инициатор) тора алалар.

1.3. Әгәр капиталь төзелеш объектына яисә күчемсез мөлкәт объектына карата бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм сату турында карар кабул ителсә, җирле бюджетны үтәгәндә субсидияләр бирү рөхсәт ителми.

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгән капиталь төзелеш объектларына яисә күчемсез мөлкәт объектларына карата карар кабул итү, соңгысы үз көчен югалткан дип танылганнан соң яисә аңа бюджет акчаларын (бюджет инвестицияләреннән субсидияләргә) бирү формасын үзгәртү белән бәйле үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.4. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларыннан, социаль-икътисади үсеш

фаразларыннан һәм программаларыннан, урта һәм озак чорга үсеш стратегияләреннән, шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең территориаль планлаштыру документларыннан чыгып, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өстенлек һәм үсеш максатларын исәпкә алып, капиталь төзелеш объектларын яисә күчемсез мөлкәт объектларын билгеләү.

1.5. Учреждениегә һәм предприятиегә бирелә торган субсидия түбәндәге эшләрне финанс белән тәэмин итүгә җибәрелми:

1.5.1. Капиталь төзелеш объектларына проект документларын эшләү яки аның турында мәгълүмат типлаштырылган проект документлары реестрына кертелгән типлаштырылган проект документларын куллану хокукларын сатып алу (торак һәм административ биналарга, социаль-мәдәни һәм көнкүреш билгеләнешендәге объектларына карата) һәм мондый проект документларын әзерләү өчен башкарыла торган инженерлык эзләнүләрен үткәрү.

1.5.2. Проект документларына һәм инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү.

1.5.3. Капиталь төзелеш объектларының смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне үткәрү, субсидия кулланып, тормышка ашыру планлаштырыла торган төзелешне (реконструкцияләүне, шул исәптән реставрация элементлары белән, яңадан техник җиһазландыруны) финанслар белән тәэмин итү.

1.6. Учреждениегә һәм предприятиегә бирелә торган субсидия, әгәр Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән башкасы каралмаган булса, әлеге тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән эшләрне финанс белән тәэмин итүгә җибәрелми.

## 2. Карар проектын әзерләү

2.1. Инициатор карар проектын Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары проекты рәвешендә әзерли.

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль программасы (ярдәмче программалар, ведомство максатчан программасы, аерым чара) кысаларында субсидия бирелгән очракта, инициатор карар проектын тиешле муниципаль программага (ярдәмче программага, ведомство максатчан программасына) кертә һәм, әгәр ул бер үк вакытта аның координаторы булмаса, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль программасы координаторы белән килештерә.

2.2. Карар проекты белән төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләү элементлары белән, техник яктан яңарту) яисә сатып алу субсидияләр рәвешендә каралаган, шул исәптән Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль программасы кысаларында, бер учреждениенең яисә предприятиенең берничә капиталь төзелеш объектлары яисә күчемсез мөлкәт объектлары карала ала.

2.3. Карар проектында түбәндәге мәгълүмат бар:

2.3.1. Проект документациясе нигезендә капиталь төзелеш объектының исеме (яисә капиталь төзелеш объектының фаразланган исеме – Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган карар проектын әзерләү датасына проект документлары булмаган очракта) яисә күчемсез мөлкәт объектының исеме.

2.3.2. Юнәлеш (бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруның максаты):

төзелеш, реконструкция, шул исәптән реставрацияләү элементлары белән, техник яктан яңарту яки күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу.

2.3.3. Төзүче, заказчы атамасы.

2.3.4. Файдалануга кертелергә тиеш капиталь төзелеш объектының куәте (куәте артуы), күчемсез мөлкәт объекты куәте.

2.3.5. Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү яисә күчемсез мөлкәт объектын сатып алу срогы.

2.3.6. Капиталь төзелеш объектының смета бәясе (расланган проект документациясе булганда) яисә капиталь төзелеш объектының фаразлана торган (иң чик) бәясе, яисә проект документациясен әзерләүгә һәм инженерлык эзләнүләрен уздыруга яисә типлаштырылган проект документациясен куллануга хокуклар сатып алуга бирелгән субсидия күләмен күрсәтеп, күчемсез мөлкәт объектын сатып алуның күздә тотыла торган (иң чик) бәясе.

2.3.7. проект документациясен әзерләүгә һәм инженер эзләнүләре үткәрүгә яисә типлаштырылган проект документациясеннән файдалану хокукын сатып алуга субсидия күләмен күрсәтеп, капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга җибәрелә торган субсидиянең гомуми (иң чик) күләме, күчемсез мөлкәт объектын сатып алуга субсидиянең гомуми (иң чик) күләме.

Карар проектында капиталь төзелеш объектлары турындагы мәгълүмат әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә чагылдырылырга тиеш, ә субсидия кулланып сатып алына торган күчемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүмат әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә чагылдырылырга тиеш.

2.4. Карар проектын әзерләү инициаторы аны Түбән Кама муниципаль районының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге, төзелеш һәм архитектура идарәсе, бюджет һәм финанслар департаменты, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең тиешле вазыйфаи затлары белән килештерә.

**Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтнең капиталь төзелеш объектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга һәм Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милеккә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә 1 нче кушымта**

## Капиталь төзелеш объекты турында мәгълүмат формасы

---

(проект документациясе нигезендә капиталь төзелеш объектының атамасы яисә капиталь төзелеш объектының фаразланган исеме –Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган карар проектын әзерләү датасына проект документлары булмаган очракта)

| Объект буенча төп техник-икътисади күрсәткечләр | | |
|---|---|---|
| 1 | Юнәлеш (бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру максаты): төзелеш, реконструкция, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник яктан яңадан коралландыру | |
| 2 | Төзүче, заказчы исеме | |
| 3 | Куллануга тапшырылырга тиешле капиталь төзелеш объектының куәте (куәте үсеше) | |
| 4 | Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру вакыты | |

| Финанс ягыннан тәэмин итү күләме | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күрсәткеч | Финаннанслау чыганагы сумнарда | Тормышка ашыру чоры | | | | |
| | | Барлыгы | алдагы чор | агымдагы ел | план чорының беренче елы | һ.б. |
| Капиталь төзелеш объектының смета бәясе (расланган проект документлары булганда) яки капиталь төзелеш объектының фаразланган (иң чик) бәясе | Барлыгы | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганаклар | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шул исәптән: | | | | | | | |
| проект документларын әзерләү һәм инженер-лык тикшеренүләре үткәрү яки типик про-ект документларын куллану хокукларын сатып алу | Барлыгы | | | | | | |
| | респуб-лика бюджеты | | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | | |
| | башка чыганак лар | | | | | | |
| Капиталь төзелеш объ-ектларына капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән субсидиянең гомуми (иң чик) күләме | Барлыгы | | | | | | |
| | республи ка бюджеты | | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| проект документларын әзерләү һәм инженер-лык тикшеренүләре үткәрү яки типик про-ект документларын куллану хокукларын сатып алу | Барлыгы | | | | | | |
| | республи ка бюджеты | | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | | |
| Капиталь төзелеш объ-ектларына капиталь кертемнәрне тормышка ашыруга юнәлдерелгән учреждение яки пред-приятие акчаларының гомуми күләме | | | | | | | |
| | респуб лика бюджет ы | | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | | |
| | башка чыганак лар | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | |
| проект документларын әзерләү һәм инженер-лык тикшеренүләре үткәрү яки типик про-ект документларын куллану хокукларын | Барлыгы | | | | | | |
| | республи ка бюджеты | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| сатып алу | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак лар | | | | | |

Искәрмә: «алдагы чор» графасында финанс белән тәэмин итү күләме елларга бүленмичә бер суммада чагыла.

Түбән Кама муниципаль районының
функциональ (тармак) бүлекчәсе җитәкчесе _______________/_________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

**Субсидия кулланып сатып алына торган күчемсез мөлкәт объекты турында мәгълүмат формасы**

__________________________________________________________________
күчемсез мөлкәт объекты исеме

| Объект буенча төп техник-икътисадый күрсәткечләр | | |
|---|---|---|
| 1 | Субсидия алучының исеме | |
| 2 | Күчемсез мөлкәт объектының куәте | |
| 3 | Күчемсез мөлкәт объектын сатып алу срогы | |

| Финанс белән тәэмин итү күләме | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күрсәткеч | Финаннанслау чыганагы сумнар- | Гамәлгә ашыру чоры | | | | |
| | | барлыгы | алдагы чор | агымдагыел | план чорының беренче елы | һ.б |
| Күчемсез милек объектын сатып алуның фаразланган (иң чик) бәясе | барлыгы | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак лар | | | | | |
| Күчемсез милек объектын сатып алуга юнәлдерелгән субсидиянең гомуми (иң чик) күләме | барлыгы | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганак лар | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга юнәлдерелгән учреждение яки предприятие акчаларының гомуми күләме | барлыгы | | | | | |
| | республика бюджеты | | | | | |
| | җирле бюджет | | | | | |
| | башка чыганаклар | | | | | |

Искәрмә: «Алдагы чор» графасында финанс белән тәэмин итү күләме еллар буенча бүленешсез бер суммада чагыла.

Түбән Кама муниципаль районы
функциональ (тармак) бүлекчәсе җитәкчесе

_________________/___________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)